СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.2019 Алабуга шәһәре № 348

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән 320 санлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда (шул исәптән аерым җыю) катнашу турында Нигезләмәне раслау хакында » карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 маддәсе, 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында » Федераль законга, 2002 елның 10 гыйнварында чыккан 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән 320 санлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда (шул исәптән аерым җыю) катнашу турында Нигезләмәне раслау хакында » карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда (шул исәптән аерым җыю) катнашу турында Нигезләмәне раслау хакында»

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда (шул исәптән аерым җыю) катнашу турында Нигезләмәне яңа өстәлә торган редакциядә расларга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны җир-милек мөнәсәбәтләре һәм табигатьне куллану мәсьәләләре буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.Е. Емельянов